**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ИРКЕНЯШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИРКӘНӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**423724, Республика Татарстан Мензелинский район, с.Старый Иркеняш, ул.Иманле, д.20**

**423724, Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Иске Иркәнәш авылы, Имәнле урамы, 20**

телефон: (85555) 2-44-41. E-mail. irk.Mnz@tatar.ru

ОКПО 93066925 ОГРН 1061682002018 ИНН/КПП 1628006581/162801001

КАРАР

«27» 03 2020 ел. №4

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Иркәнәш авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасының "Җирле референдум турында"гы 23-ЗРТ номерлы Законы, Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иркәнәш авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иркәнәш авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.
2. Әлеге карар рәсми төстә басылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә йөклим.

Авыл җирлеге башлыгы Камалов И.З..

ТР Минзәлә муниципаль районы
Иркәнәш авыл җирлеге
Башкарма комитеты
Карарына 1 нче кушымта
дата 27.03 2020 ел. N 4

ТР Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарга үзара салым акчаларын түләтү Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм инвалидлардан, шулай ук 1 төркем инвалидлардан тыш, 18 яше тулган, Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәре территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуына һәм тавыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтенә бәйсез рәвештә, 31 мартка кадәр срокта башкарыла.

3. Аерым категорияле гражданнар өчен:

- Бөек Ватан сугышы ветераннары;
- Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары,
- 1 һәм 2 төркем инвалидлар;
- биш һәм аннан күбрәк балалы күпбалалы әниләр.

Җитди сәбәпләр булганда, аларга түбәндәгеләр керергә мөмкин:

а) авыру;

б) озакка сузылган командировка;

өч айдан артмаган срокка гариза нигезендә гражданнарга түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр язуы (уведомление) бланкы Җирлекнең мәгълүмати стендында, Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең menselinsk.tatarstan.ru рәсми сайтында бастыру, шулай ук имза куйдырып тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән гражданнарга житкерелә.

5. Хәбәр язуында (уведомление) гражданнарның үзара салым акчаларын кертүгә түләү реквизитлары, тулысынча яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү күләме, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш (Кушымта).

6. Гражданнарның үзара салымнан кергән акчалата чаралары Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең лицевой счетына керә.

7. Гражданнардан түләү алу почта (хисап оешмалары) переводларын башкаруга физик затларның йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясауга хокукы булган оешмалар, Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы, https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша акчаларны күчерү юлы белән башкарыла.

8. Касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслаучы булып тора.

9. Билгеләнгән срокта гражданнардан алынмаган үзара салым акчалары законда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

2 нче кушымта

ХӘБӘР ЯЗУЫ (УВЕДОМЛЕНИЕ) N _______________ Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү кертү турында

түләученең Ф.Ис.Ат.ис. ______________________________________________

Адресы: ______________________________________________

______________________________________________ нигезендә

Сезгә ____________ срокка кадәр ______________________ чараларны гамәлгә

______________________________________ ашыруга бер тапкыр түләү кертергә кирәк.

суммада _______________ сум, түбәндәге реквизитлар буенча:___________________

Түләү алучы банкның БИК ______________________________________________
Сч. N ______________________________________________
Кабул итүче Сч. N ______________________________________________
КПП ______________________________________________
КБК _______________ ОКАТО _________________
Түләү билгеләнеше ______________________________________________
Җитәкче _______________ ______________________________________
М.У. (имза) (тулысынча имза)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәр язуы (Уведомление) N _________________
Үзара салым буенча бюджетка бер тапкыр түләү кертү турында _____________________
______________________________________________
(муниципаль берәмлек атамасы)
суммада ________________ сум.

түләученең Ф.Ис.Ат.ис. ______________________________________________
Адресы: ______________________________________________
Алдым "___" _______________ 20___ ел. ______________________________________

____________________
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Хәбәр язуы төпсәсе (корешок) тутырыла һәм хәбәр язуы түләүченең шәхсән үзенә тапшырылган очракта, Башкарма комитетта кала.